ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ
ул. Карима Тинчурина, д. 29, г. Казань, 420021

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ
К. Тинчурин ур., 29 йорт, Казан шәһәре, 420021

Телефон: (843)211-66-94, факс: (843)211-66-47, E-Mail:ojm@tatar.ru, сайт:http://ojm.tatarstan.ru

Приказ Казан шәһәре Боерык

03.12.2025 № 288-од

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2023 елның 13 ноябрендәге 315-од номерлы боерыгы белән расланган, Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты тарафыннан идарә ителә торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының норматив хокукый актын федераль законнарга туры китерү максатларында, «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 6 маендагы 393 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 10 октябрендәге 1360 номерлы карарын кабул итүгә бәйле рәвештә боерам:

1. Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2023 елның 13 ноябрендәге 315-од номерлы боерыгы белән расланган, Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты тарафыннан идарә ителә торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибенә кертелә торган теркәлгән үзгәрешләрне (Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2024 елның 25 сентябрендәге 257-од номерлы боерыгы белән

белән кертелгән үзгәрешләр белән) расларга.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары Р.Г. Шәрәфетдиновка йөкләргә.

Рәис Ф.С. Батков

Татарстан Республикасы
Биологик ресурслар буенча
дәүләт комитетының
_2025__ елның _03
декабрендә _288-од
номерлы боерыгы белән
расланган

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты тарафыннан идарә ителә торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибенә кертелә торган үзгәрешләр

4 нче пунктта:

1 пунктчада «Дәүләт комитеты хисаплылыгыннан өземтәләрне» сүзләрен «белешмәләрне» сүзенә алмаштырырга;

2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр, алар буенча Россия Федерациясе Бюджет кодексының Дәүләт комитетының тиешле административ керем чыганагы беркетелгән структур бүлекчәсе тарафыннан әзерләнгән $160^1$ статьясы нигезендә билгеләнгән пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләтүне тәэмин итү буенча күрелгән чаралар турында Дәүләт комитеты белешмәләре»;

3 нче пунктча:

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«штраф рәвешендә җәзага хөкем ителгәннәргә карата амнистия яки ярлыкау турында акт яисә бюджет керемнәре администраторы бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтү мөмкинлеген югалта торган суд карары, шул исәптән аны түләтүнең билгеләнгән срогы тәмамлануга бәйле рәвештә;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«гражданның судтан тыш банкротлыгы процедурасын тәмамлау турында банкротлык турындагы белешмәләрнең бердәм федераль реестрыннан белешмәләр булган документ».